**МИНИСТЕРСТВО ЭКОЛОГИИ
И ПРИРОДНЫХ РЕСУРСОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЭКОЛОГИЯ ҺӘМ ТАБИГЫЙ
БАЙЛЫКЛАР МИНИСТРЛЫГЫ**

**ПРИКАЗ** г. Казань **БОЕРЫК**

12.02.2016 119-п

Татарстан Республикасының Экология һәм табигый ресурслар министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәткәрләре тарафыннан вазифаи вәкаләтләрне үтәгәндә мәнфәгатьләр каршылыгына китерә торган яки китерергә мөмкин булган шәхси кызыксынучанлык барлыкка килү турында хәбәр итү тәртибен раслау хакында

2008 елның 25 декабрендәге “Коррупциягә каршы көрәш турында” № 273-ФЗ Федераль закон, Россия Федерациясе Президентының 2015 елның 22 декабрендәге “Россия Федерациясенең аерым дәүләт вазифаларын, федераль дәүләт вазифаларын биләүче затлар һәм бүтән затлар тарафыннан вазифаи вәкаләтләрне үтәгәндә мәнфәгатьләр каршылыгына китерә торган яки китерергә мөмкин булган шәхси кызыксынучанлык барлыкка килү турында хәбәр итү тәртибе турында һәм Россия Федерациясе Президентының кайбер актларына үзгәрешләр кертү хакында” № 650 Указы нигезендә боерык бирәм:

1. Кушымта булып килүче Татарстан Республикасының Экология һәм табигый ресурслар министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәткәрләре тарафыннан вазифаи вәкаләтләрне үтәгәндә мәнфәгатьләр каршылыгына китерә торган яки китерергә мөмкин булган шәхси кызыксынучанлык барлыкка килү турында хәбәр итү тәртибен расларга (алга таба – Тәртип).

2. Хокукый тәэминат бүлегенә (В.А. Тронин) шушы боерыкның Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгында дәүләт теркәвенә алынуын тәэмин итәргә.

3. Дәүләт хезмәте һәм кадрлар бүлегенә (Сәлимгәрәев Ш.К.) шушы боерык белән Татарстан Республикасы Экология һәм табигый ресурслар министрлыгындагы дәүләт гражданлык хезмәткәрләрен, шулай ук алар белән хезмәт контрактларын төзегәндә гражданнарны таныштыруны тәэмин итәргә.

4. Дәүләт хезмәте һәм кадрлар бүлегенең әйдәп баручы киңәшчесенә - коррупция һәм башка төрле хокук бозуларны кисәтү буенча җаваплы затка (Г.Р. Аблеева) Татарстан Республикасының Юстиция министрлыгында теркәлгәннән соң 7 көнлек срокта Татарстан Республикасы Экология һәм табигый ресурслар министрлыгының 14.03.2014 № 170-п боерыгы белән расланган Татарстан Республикасының Экология һәм табигый ресурслар министрлыгында Дәүләт гражданлык хезмәткәрләренең хезмәт тәртибенә карата таләпләр үтәлеше һәм мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салу буенча комиссиясе турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертергә; шушы боерыкны Татарстан Республикасы Экология һәм табигый ресурслар министрлыгының "Интернет" мәгълүмати-телекоммуникацияләр челтәрендәге сайтында, "Коррупциягә каршы көрәш" бүлегендә урнаштырырга.

5. Әлеге боерык үтәлешен контрольдә тоту җаваплылыгын үз өстемә алам.

Министр Ф.С. Габделганиев

Татарстан Республикасы
Экология һәм табигый
ресурслар министрлыгының
12.02.2016 №119-п боерыгы
белән расланды

Татарстан Республикасының Экология һәм табигый ресурслар министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәткәрләре тарафыннан вазифаи вәкаләтләрне үтәгәндә мәнфәгатьләр каршылыгына китерә торган яки китерергә мөмкин булган шәхси кызыксынучанлык барлыкка килү турында хәбәр итү тәртибе

1. Әлеге Тәртип Татарстан Республикасының Экология һәм табигый ресурслар министрлыгында (алга таба – Министрлык) аларга карата эшкә алучының вәкиле булып Татарстан Республикасы экология һәм табигый ресурслар министры (алга таба – министр) торган Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәткәрләре (алга таба – граждан хезмәткәрләре) тарафыннан вазифаи вәкаләтләрне үтәгәндә мәнфәгатьләр каршылыгына китерә торган яки китерергә мөмкин булган шәхси кызыксынучанлык барлыкка килү турында хәбәр итү тәртибен регламентлый.

2. Хәбәр гражданлык хезмәткәрләре тарафыннан шушы Тәртипкә карата Кушымтада китерелгән вазифаи вәкаләтләрне үтәгәндә мәнфәгатьләр каршылыгына китерә торган яки китерергә мөмкин булган шәхси кызыксынучанлык барлыкка килү турында белдерүнамә (алга таба – белдерүнамә) рәвешендә язмача төзелә һәм Министрга җибәрелә.

3. Министр өч эш көне дәвамында белдерүнамәне беренчел карап тикшерү өчен коррупцияне һәм башка төрле хокук бозуларны кисәтү буенча эш өчен җаваплы затка (алга таба – җаваплы зат) җибәрә.

4. Белдерүнамәне беренчел карап тикшерү барышында җаваплы зат белдерүнамәне җибәргән гражданлык хезмәткәреннән анда бәян ителгән шартлар буенча аңлатмалар алырга, билгеләнгән тәртиптә дәүләт хакимияте органнарына, башка җирле үзидарә органнарына һәм кызыксынган оешмаларга гарызнамәләр җибәрүнең инициаторы булырга хокуклы.

5. Белдерүнамәне беренчел карап тикшерү нәтиҗәләре буенча җаваплы зат нигезле бәяләмә әзерли. Беренчел карап тикшерү барышында алынган белдерүнамә, бәяләмә һәм башка материаллар җаваплы зат белдерүнамәне алган көннән башлап җиде эш көне дәвамында аның тарафыннан Татарстан Республикасының Экология һәм табигый ресурслар министрлыгында Дәүләт гражданлык хезмәткәрләренең хезмәт тәртибенә карата таләпләр үтәлеше һәм мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салу буенча комиссиясе (алга таба – Комиссия) рәисенә тапшырыла.

6. Шушы Тәртипнең 4 пунктында күрсәтелгән гарызнамәләрне җибәргән очракта, бәяләмә һәм башка материаллар җаваплы зат тарафыннан Комиссия

рәисенә белдерүнамәне алган көннән соң 45 көн дәвамында тапшырыла. Аталган вакыт Комиссия рәисе тарафыннан 30 көннән артмаган чорга озынайтылырга мөмкин.

7. Белдерүнамә, бәяләмә һәм башка материаллар Комиссия тарафыннан Татарстан Республикасы Экология һәм табигый ресурслар министрлыгының боерыгы белән расланган Татарстан Республикасының Экология һәм табигый ресурслар министрлыгында Дәүләт гражданлык хезмәткәрләренең хезмәт тәртибенә карата таләпләр үтәлеше һәм мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салу буенча комиссиясе турында нигезләмә нигезендә карап тикшерелә.

Татарстан Республикасының
Экология һәм табигый ресурслар
министрлыгында Татарстан Республикасы
дәүләт гражданлык хезмәткәрләре тарафыннан
вазифаи вәкаләтләрне үтәгәндә
мәнфәгатьләр каршылыгына китерә
торган яки китерергә мөмкин булган
шәхси кызыксынучанлык барлыкка килү
турында хәбәр итү тәртибенә карата
кушымта

Татарстан Республикасының
экология һәм табигый ресурслар
министрына

кемнән ______________________________
(вазифаның аталышы)
_____________________________________
(Ф.И.А., адресы, телефон номеры)

## Вазифаи вәкаләтләрне үтәгәндә мәнфәгатьләр каршылыгына китерә торган яки китерергә мөмкин булган шәхси кызыксынучанлык барлыкка килү турында белдерүнамә

Вазифаи вәкаләтләрне үтәгәндә миндә мәнфәгатьләр каршылыгына китерә торган яки китерергә мөмкин булган шәхси кызыксынучанлык барлыкка килү турында хәбәр итәм (кирәклесе астына сызарга).

Шәхси кызыксынучанлык барлыкка килү өчен нигез булган шартлар: ______________________________________________________________________
____________________________________________________________

Шәхси кызыксынучанлык аларның үтәлешенә йогынты ясый яки ясарга мөмкин булган вазифаи вәкаләтләр ___________________________________
______________________________________________________________________
____________________________________________________________

Мәнфәгатьләр каршылыгын бетерү яки җайга салу буенча тәкъдим ителә торган чаралар:_____________________________________________
______________________________________________________________

Шушы белдерүнамәне карап тикшергәндә Татарстан Республикасы экология һәм табигый ресурслар министры карамагындагы Дәүләт гражданлык хезмәткәрләренең хезмәт тәртибенә карата таләпләр үтәлеше һәм мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салу буенча комиссиясе утырышында шәхсән катнашырга ниятлим / ниятләмим (кирәклесе астына сызарга).

| _________ | ______________________ | ______________________ |
|---|---|---|
| (дата) | (белдерүнамә җибәргән затның имзасы) | (имзаның аңлатмасы) |